| ГЛАВА<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.02.2019 с.Старое Дрожжаное № 10

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иҗтимагый советы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасында коррупциягә каршы эшчәнлекне координацияләү буенча Комиссиянең 2018 елның 24 сентябрендәге утырышы Беркетмәсенә туры китереп, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының 2014 елның 22 сентябрендәге 36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иҗтимагый советы турындагы Нигезләмәгә, унөченче абзацның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге өстәмә кертеп, үзгәреш кертәргә:

«- коррупциягә каршы профилактикага һәм эшчәнлеккә юнәлтелгән чараларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Чүпрәле муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Э.С.Әхмәтовка йөкләргә.

Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы М.Р. Гафаров